ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 май 2026 ел № 565

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 01 мартындагы 224 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 01 мартындагы 224 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 апрелендәге 476 номерлы, 2024 елның 13 декабрендәге 1514 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет турында күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

3 бүлекнең 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3.9. Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хезмәте Вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган башка затлар керә алмый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин